СОВЕТ ЗИРЕКЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 53,
с. Ерыклы, 423185

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗИРЕКЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Ленин урамы, 53,
Зирекле авылы, 423185

тел., факс: (8-4348) 38-6-76, zarek.nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
Зирекле авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2022 елның 31 октябреннән № 26-86

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге Советының 2022 елның 29 нчы августында 24-82 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге Советының 2022 елның 29 нчы августында 24-82 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында нигезләмәгә түбәндәге узгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 статьяның 1 пунктындагы 13 пунктчасын төшереп калдырырга;

1.2. 9 статьяның 2 пунктында «муниципаль берәмлек» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге (алга таба – Җирлек)» сүзләрен өстәргә;

1.3. 10 статьяның 1 пунктында «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» сүзләрен «Җирлек» сүзе белән алыштырырга;

1.4. 10 статьяның 3 өлешенең икенче җөмләсен төшереп калдырырга;

1.5. 15 статьяның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге» сүзләрен «Җирлек» сүзе белән алыштырырга;

1.6. 17 статьяның 1 өлешендәге 10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10) үз керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук гамәлдәге законнар нигезендә хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә.»;

1.7. 20 статьяның 1 пунктында «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль

районы» сүзләрен «Җирлек» сүзе белән алыштырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, шулай ук Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга: http://novosheshminsk.tatarstan.ru.

3. Бу карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге Советының Законлылык, экология, Җирдән файдалану, торак - коммуналь хуҗалык һәм территорияне төзекләндерү мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Зирекле авыл җирлеге башлыгы

СОВЕТ ЗИРЕКЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Җ.Г. Гайфетдинов